Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«14» ноябрь, 2025 ел № 2

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 45,69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Боерган авыл җирлегенең 29.10.2019 ел 49/2 номерлы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Боерган авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары нигезендә Боерган авыл җирлеге Боерган авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2026 елда яшәү урыны буенча Боерган авыл җирлеге Боерган авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең)сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- урамнарны яктырту җайланмасы(СИП сузу, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны проектлау, төзү һәм ремонтлау(Боерган авылы Мирная, Х. Галиев урамнарындагы суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау);
-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Боерган авылы Яңа урамындагы юлга ком-гравий катнашмасы сибү)

2. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты
Җитәкчесе Г.Г.Минакова